*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 49**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Саңгырау тартыклардан гына торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) [р], [л], [м], [н]
2) [п], [к], [с], [ч]
3) [з], [щ], [х], [һ]
4) [ф], [т], [ш], [д]

2. Рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) валчык
2) тимераяк
3) тәрәзә
4) болынлыкта

3. *Юл* сүзендә ю хәрефе нинди аваз белдерүен билгеләгез. **(2 балл)**
1) [у] авазын
2) [йү] авазын
3) [йу] авазын
4) [ү] авазын

4. Юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алма
2) уңыш
3) каен
4) тиен

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Татар хатын-кызларыны төсле җепләр белән чигелгән, сәйлән белән бизәлгән баш киеме*
1) калфак
2) бүрек
3) яулык

4) башлык

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Үз халкын сөймәгән*
1) аптырап утырган.
2) ерак киткән.
3) телен белгән.
4) башка халыкны да сөймәс.

7. Синоним сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) матур, чибәр
2) кайнар, салкын
3) сөйләшү, йөгерү
4) ак, кара

8. *Кар* сүзенә тамырдаш булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) карга
2) карлы
3) карандаш
4) кара

9. Юнәлеш килеше кушымчалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) -ның/-нең
2) -га/-гә, -ка/-кә
3) -ны/-не
4) -да/-дә, -та/-тә

## II. Теоретик бирем.

Антонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(5 балл)**

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм килеш кушымчасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) урман | 1) -тан |
| Ә) китап | 2) -дан |
| Б) бала | 3) -нан |
| В) әти | 4) -нән |
| Г) энем | 5) -дән |

**Җавап :** ___________________________

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Үрмәкүч челтәрдән өй үреп, агач башына (куйган / элгән / ясаган). Бөҗәкләр, сокланып:

- Нинди матур өй, безнең мондый матур өйне беренче тапкыр күрүебез, - дигәннәр.

Тик чебен генә бер сүз дә (сөйләмәгән / дәшмәгән / уйламаган). Аның ничек тә булса үрмәкүч оясын урлыйсы килгән һәм аны үрмәкүче белән күтәреп алып китмәкче булган. Тик үзе уралып калган, котылырга теләп чәбәләнгән саен ныграк кына (югалган / уралган / баткан) һәм һәлак булган.

Кеше (өенә / малына / матурлыгына) кызыксаң, шулай була ул.

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Тәр ... зәгә күз салдым –
Бик нык гаҗәпкә калдым:
Бозау х ... тле сап-сары эт,
... фрагын җы ... п талның,
Өй кереште күшәргә,
Инде миңа нишләргә? (*Ф. Тарханова*)

3. Шигырьдән *карадым* сүзенең синонимын күчереп языгыз. **(2 балл)**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

4. *Нишләргә* сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. **(4 балл)**

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

5. “Туган ягым” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2023-2024 нче уку елы 5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 54**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Яңгырау тартыклардан гына торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) [р], [л], [м], [н]
2) [п], [к], [с], [ч]
3) [к], [щ], [х], [һ]
4) [ф], [т], [ш], [д]

2. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) бозгыч
2) көндәлек
3) тәрәзә
4) өстәлдә

3. Нечкә сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Бердәмлектә көч.
2) Бергә эшләсән, авыр эш тә җиңел.
3) Дуслык - зур байлык.
4) Өйнең яме ана белән.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) уйла
2) китап
3) хикәя
4) җирдән

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Күннән яки башка йомшак материалдан эшләнгән үкчәсез җиңел һәм йомшак аяк киеме.*
1) киез итек
2) ботинка
3) чүәк
4) күн итек

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**

*Уңга киткән уңар,*

1) сулга киткән югала.
2) сулга киткән туңар.
3) үз дустын табар.
4) сулга борылып карамас.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Безнең Кәрим бик башлы булып чыкты.* (З.Бәшири)

1) булдыклы
2) эшчән
3) белемле
4) тырыш

8. Тамыр сүз күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

1) күрсәтмә
2) якташ
3) болын
4) карабодай

9. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә каарвын билгеләгез. **(2 балл)**

*Безнең бакча коймасына **сигез** карлыгач кунды. (З. Нури)*

1) исем
2) сан
3) сыйфат
4) фигыль

10. Җөмләдәге тәмамлыкны билгеләгез. **(2 балл)**

*Икмәкне кешеләр тир түгеп табалар*.

1) икмәкне
2) кешеләр
3) тир түгеп
4) табалар

## II. Теоретик бирем.

Синонимнар турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Җөмләләр һәм сүзлекләрне тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) Матур – ямьсез. | 1) Аңлатмалы сүзлек |

| | |
|---|---|
| Ә) Даруханә – аптека. | 2) Татарча – русча сүзлек |
| Б) Давыл, өермә, гарасат. | 3) Русча – татарча сүзлек |
| В) Окно – тәрәзә. | 4) Антонимнар сүзлеге |
| Г) Кунак – махсус чакырылган яисә күрешү өчен читтән килгән кеше. | 5) Синонимнар сүзлеге |

**Җавап :** ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Койма (тактасына / өстенә / баганасына) сары буяу белән буяп ясалган Кояш күк йөзендәге кара-кучкыл болытларга дәште:

- Әй, болытлар, күрәсезме мине? Мин – Кояш! Мин кояшларның да кояшы!

Коймадагы Кояш бөтерелә-бөтерелә чыркылдаган Чыпчыкка дәште:

- Әй, чыркылдык, күрәсеңме мине? Мин – Кояш! Кара миңа, (гаҗәплән / соклан / уйлан)! Миңа һәр кеше сокланып карый.

Кара-кучкыл болытларга коймадагы кояшның шулай әрсезләнеп (әйтүе / шапырынуы / кычкыруы) ошамады. Алар шыбыр-шыбыр яңгыр яудыра башладылар. “Бу – мин... мин...” – дип бытылдаган Кояшны яңгыр тамчылары коймадан ( бер сәгатьтә / күз ачып йомганчы / көн дәвамында) юып төшерде. (*Н. Каштаннан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Оф...клар чал, болытлар чал,
Чал диңгез яры.
Көтә безне карлы-бозл...
Төн...як причалы.

Бо...ваткычсыз җибәрми боз
Корабны ярга.
Туза карлар, бо...ваткычлар
Безгә юл яра. (*Ф. Тарханова*)

3. Шигырьдән рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(4 балл)**

___________________________________________

4. *Җибәрми* сүзен мәгънәви кисәкләргә таркатыгыз, нинди сүз төркеменә каравын, төрләнешен билгеләгез. **(4 балл)**

___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________
___________________________________________

5. “Яраткан китабым” темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 56**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Кече тел тартыгын билгеләгез. **(2 балл)**
  1) [х]
  2) [т]
  3) [һ]
  4) [ф]

2. Авазлар һәм хәрефләр саны туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алъяпкыч
2) юрган
3) йорт
4) вакыйга

3. Калын сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Һәр эшнең ахырын уйла.
2) Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел.
3) Дуслык - зур байлык.
4) Ил эче – алтын бишек.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) күренмәдегез
2) татарча
3) язмыйбыз
4) укучылар

5. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Бизәкләп эшләнгән, җиңел, сай түгәрәк ир-ат баш киеме.*
1) эшләпә
2) бүрек
3) түбәтәй
4) башлык

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөньяда иң йомшак нәрсә* -
1) яңа яуган кар.
2) әнием кулы.
3) ак мамык.
4) үзең эшләгән мендәр.

7. Җөмләдәге фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Безнең Кәрим бик башлы булып чыкты.* (З.Бәшири)
1) булдыклы
2) эшчән
3) белемле
4) тырыш

8. Җөмләдәге омонимның төрен билгеләгез.
*Кара, төньяктан кара болыт килә.*
1) саф
2) омоформа
3) омографлар
4) омофон

9. Җөмләдәге сыйфатларның дәрәҗәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөньяда иң ачы нәрсә дә – тел, иң татлы нәрсә дә – тел.* (Мәкаль)
1) гади
2) чагыштыру
3) артыклык
4) кимлек

10. *Мин базардан карбыз, кавын һәм кыяр сатып алдым* җөмләсендәге ия белән хәбәрнең сүз төркемнәрен билгеләгез. **(2 балл)**
1) ия – исем, хәбәр – фигыль
2) ия – алмашлык, хәбәр – фигыль
3) ия – сан, хәбәр – исем
4) ия – сыйфат, хәбәр – фигыль

## II. Теоретик бирем.

Сан сүз төркеме, аның төркемчәләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүз һәм авазларны тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) ал...япкыч | 1) һ |

| | |
|---|---|
| Ә) мә...ге | 2) а |
| Б) җәү...әр | 3) ң |
| В) к...нәфер | 4) ә |
| Г) җ...мәгать | 5) ъ |

**Җавап :** ___________________________

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Безгә аклы-сарылы песи баласы кереп (урнашты / җитте / ияләште). Безнең үзебезнең бер песиебез бар иде инде. Ул песиебез үзе ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Без аны матурлыгы өчен генә түгел, акыллылыгы өчен дә яратабыз. Ул, үзе бик (шаян / тәртипле / тыңлаучан) булса да, ашамлыкка тими. Күршеләргә дә кереп йөрми. Ә күршедән кергән песи бик тәртипсез булып чыкты. Бертуктаусыз «мияу-мияу» ди. Ашарга бирсәң, төрле җиргә тарата башлый да идәнне (буйый / пычрата / ямьсезли). Өстәлгә менеп, икмәк сыныкларын тартып төшерә. Тагын әллә нинди тәртипсезлекләр эшли. Беркөнне минем белән уйнарга иптәш кызым Мәйсәрә керде. Ул:

— Бу юньсез песине нигә керттегез? Ул инде бик күп кешегә йөрде. Бездә дә булды. Аны (гаять / бөтен / әллә) кеше дә куып чыгарды. Ул — акылсыз, сөйкемсез песи,— диде. (*Ә. Бикчәнтәевадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Уйламыйча дустым бер сүз әйтте,
Ул сүз йөрәгемә ка....алды.
Үзе берни белми китеп барды.
Ә сүз калды.

Ул сүз тора минем йөрәгемдә
(А....нан авыр яра юк сыман).
Җә...сеннән ...лгыш атылып киткән
Һәм дустына тигән ук сыман.

(*И. Юзеев*)

3. *Калды* сүзен мәгънәви кисәкләргә таркатыгыз, нинди сүз төркеменә каравын, төрләнешен билгеләгез. **(4 балл)**

___________________________________________

___________________________________________

___________________________________________

5.Шигырьнең икенче куплетыннан исем сүз төркеменә караган сүзләрне күчереп языгыз. **(6 балл)**

6. “Нәни дусларыбыз ярдәм көтә” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. **(10 балл)**

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының
муниципаль туры биремнәре
2023-2024 нче уку елы
7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 55**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Киң әйтелешле [о] авазы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) торна
2) торт
3) тояк
4) торма

2. Җөмләдә кече тел тартыгы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Мәгърифәт өстәр, иренмәс һич кеше булган кеше (Г. Тукай)*
1) мәгърифәт
2) өстәр
3) иренмәс
4) кеше

3. *көмеш* сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган рәтне билгеләгез. (**2 балл**)
1) көмеш кашык
2) көмеш алка
3) көмеш беләзек
4) көмеш тамчы

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Киемнәрне пычранудан саклар өчен алга киелә яки билгә бәйләп куела торган япма*
1) күлмәк
2) камзул
3) алъяпкыч
4) бишмәт

5. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кочак җәеп*
1) тиз генә

2) шатланып
3) киң күңелле
4) ачуланып

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Акыллы өйрәнер,*
1) күп белем алыр.
2) еракка китәр.
3) ахмак өйрәтер.
4) тиз аңлар.

7. Әйтү максаты ягыннан тойгылы җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Алар бүген дәрескә соңга калдылар.
2) Бүген сез дәрестән соң киногa барасызмы?
3) Күрегезче, нинди матурлык!
4) Озын караңгы төннәр башланды.

8. Иялек килешендәге исем кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Кыюлык – адәмнең канаты.
2) Кеше күңеле – караңгы төн.
3) Картлар сүзен кар басмас.
4) Тәвәккәллек көч бирә.

9. Җөмләдәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**
*Икмәк сүзе .... ана исеме белән янәшә торырлык олы сүз.*
1) өтер
2) өндәү
3) нокта
4) сызык

10. Җөмләдәге тәмамлыкны билгеләгез. **(2 балл)**
*Алсу шигырьне дәрестә кычкырып сөйләде.*
1) Алсу
2) шигырьне
3) дәрестә
4) сөйләде

## II. Теоретик бирем.

Хәбәр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**5 балл)**

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Алмашлыклар һәм аларның төркемчәләрен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) берәү | 1) зат алмашлыгы |
| Ә) һич | 2) билгеләү алмашлыгы |
| Б) һәр | 3) сорау алмашлыгы |
| В) нәрсә | 4) билгесезлек алмашлыгы |
| Г) миңа | 5) юклык алмашлыгы |

**Җавап :** ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Сәгать алты тулар-тулмас иртәнге прогулкага чыгып барганда, күрше фатирга звонок биреп торучы карчыкка (күзем төште / йөзем борылды / күзем бактым). Звонок (урыны / төймәсе / ноктасы) шактый биектә, ә әбинең буе тәбәнәк кенә: ул, аяк очларына басып, өскә үрелгән. Язгы пальто өстеннән (кунган / бөркәнгән / җәелгән) ак шәле җилкәсенә җыерылып төшкән. Карчык, кулын звонок төймәсеннән алмый гына, миңа текәлеп карап куйды. Йөзе борчулы, күз карашында ниндидер өметсезлек, аптыраш сизелә иде. Болай да ябык, җыйнак гәүдәсе ниндидер борчудан (аптырап / куырылып / ямьшәеп) калган кебек күренә. (*Р. Хафизовадан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Кыр казлары, кая очасыз сез?
Берегез алда, берегез артта сез.
Кыйгылдашып, сез нәрсәне болай,
Күмәкләшеп, җигелеп тартасыз?
Беләм, беләм, җәйне тартасыз сез
Чинар үскән диңгез бу...на,
Магнолиял...р үскән бакчаларга,
Йөз...м үскән та...лар куенына. (*Ә. Фәйзи*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп языгыз. (**2 балл**)

______________________________________________________________

4. Рус теле аша кергән Европа алынмасын күчереп языгыз. (**2 балл**)

______________________________________________________________

5. *Бакчаларга* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ языгыз. **(4 балл)**

______________________________________________________________

6. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

_________________________________________________________________

7. “Кышкы табигатьтә” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2023-2024 нче уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Менә бервакыт, агач яфракларын учы белән сыпырып, җил узып китә. (Ф.Яруллин)*
1) бервакыт
2) яфракларын
3) сыпырып
4) китә

2. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) чишмә
2) тәэсир
3) хәтер
4) багланыш

3. Кушылып языла торган сүзне билгеләгез. (**2 балл**)
1) бил бау
2) аллы гөлле
3) миләш чыпчыгы
4) рәхим шәфкать

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Чәч толымына кушып үрә торган бауга яки тасмага таккан тәңкәләр*
1) изү
2) алка
3) чулпы
4) чәчүргеч

5. Җөмләдәге алынма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Никадәр шигырь, күпме роман язылган икмәк турында! (Н.Дәүли)*
1) күпме

2) шигырь
3) язылган
4) икмәк

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Сүз күп җирдә*
1) эш гөрләп бара.
2) бар да эшчән.
3) кешегә урын юк.
4) эш аз була.

7. Җөмләдәге тезмә сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Кинәт мәче башлы ябалак ук кебек аска томырыла. (М.Закиров)*
1) аска томырыла
2) мәче башлы ябалак
3) ук кебек
4) кинәт томырыла

8. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнең килешен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кинәт каядыр колагына серле аваз чалынгандай булды. (Р.Мөхәммәдиев)*
1) юнәлеш
2) төшем
3) чыгыш
4) иялек

9. Ике составлы җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Ишек шакыйлар.
2) Төн. Караңгылык.
3) Арытты.
4) Балалар укыйлар.

10. Җөмләдәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
*Су буйлап сузылган авыл урамын кисеп чыгуга ... дуслар Сары тауга күтәрелә башладылар.*

Җавап: ____________

**II. Теоретик бирем.**

Затланышлы фигыльләр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(6 балл)**

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Рәвешләр һәм аларның төркемчәләрен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) түбән | 1) охшату-чагыштыру рәвеше |
| Ә) әкрен | 2) вакыт рәвеше |
| Б) әрәмгә | 3) урын рәвеше |
| В) инглизчә | 4) сәбәп-максат рәвеше |
| Г) тиздән | 5) саф рәвеш |

**Җавап :** ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Март ахыры (килгәч / якынлашкач / беткәч), беренче зур яңалык шул булды: кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән, ә каймага зәңгәр таплар (куелган / тезелгән / бизәнгән). Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр (уянды / торды / килде), кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә – үрмәкүч (чыга / терелә / күренә), кичен суыта – ул тагы үлеп куя. Бу төр үрмәкүчләрне сукбай дип йөртәләр, чөнки алар бөҗәкләрне (баусыз / җәтмәсез / җепсез) аулыйлар. (*Г. Хәсәновтан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Уйнар идем, гармуным юк,
Җырлар идем – та...ышым.
Кисеп алып курай ит...ем
Елгабызның камышын.
Камыш курай эчләрендә
Күпме м...ң булган икән!
Ул камышка җәйләр буе
Күпме кош ку...ган икән? (*Ф. Яруллин*)

3. Тойгылы җөмләне күчереп языгыз. (**2 балл**)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

4. *Елгабызның* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

___________________________________________________________________________

5. *Кош* сүзенә 2 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(2 балл)**

___________________________________________________________________________

6.  Шигырьдән алынма сүзне күчереп языгыз. **(2 балл)**

_________________________________________________________________________

7.“*Минем хыялым*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2023-2024 нче уку елы 9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 62**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге тартыклар чиратлашуы күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Ирке чикләнмәгән йөрәгемә*
*Башлык итеп куйдым гакылны*. (Һ.Такташ)

1) йөрәгемә
2) ирке
3) башлык
4) куйдым

2. Күчерелмә мәгънәдә килгән сүзе булган җөмләне табыгыз **(2 балл).**

1) Туганнарыбыз шәһәргә килгән иде.
2) Без яшелчәләргә су сибеп йөрибез.
3) Апам, бернигә дә карамыйча, инша язуын дәвам итте.
4) Бу арада аларда буран уйный әле.

3. Орфографик хатасы булган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

1) нисбат
2) кодрәт
3) милләт
4) теләк

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Беләккә кидерелә торган, боҗра рәвешендәге бизәнү әйбере*

1) алка
2) изү
3) йөзек
4) беләзек

5. Мәкальдәге фигыльнең төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Телеңне тезгендә тот, этеңне чылбырда тот.*

1) боерык фигыль
2) хикәя фигыль
3) шарт фигыль
4) хәл фигыль

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Иренгән ике эшләгән,*
1) һаман эше пешмәгән.
2) барысына да өлгергән.
3) икесе дә барып чыккан.
4) йокысын да туйдырган.

7. Синтетик иярченле кушма җөмлә белән белдерелгән мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Гаебенә күрә җәзасы.
2) Гаеп онытылыр, сабагы калыр.
3) Үзе абынган еламас.
4) Яраткан күңелдә ялган булмый.

8. Җөмләдәге фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Ул апасы әйткәннәрне колакка да элмәде.*
1) тырышмау
2) тыңламау
3) үпкәләтү
4) кайтмау

9. Җөмләдә кулланылган сыйфат фигыльне күчереп языгыз. **(2 балл)**
*Әйтерсең безнең егерме ике кеше укыган сыйныфта Кәримовтан кала барысы да «биш»легә генә укый!*
Җавап: _____ ________

10. Иярченле кушма җөмләнең төзелеше ягыннан төрен языгыз. **(2 балл)**
*Апа сөйли башлауга, керфекләрем оеп-оеп китә.*
Җавап: _____________

## II. Теоретик бирем.

Җөмләнең иярчен кисәкләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**6 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүзләр һәм аларның ясалыш ысулларын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) көнбагыш | 1) тамыр сүз |
| Ә) пыяла | 2) ясалма сүз |
| Б) сиртмә койрык | 3) саф кушма сүз |
| В) тозсыз | 4) тезмә сүз |
| Г) әйлән-бәйлән | 5) парлы |

**Җавап : _________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Мин яр өстеннән елгага карап торам. Ык тын гына (бара / ага / шаулый). Баеп баручы кояш, елга өстеннән нәрсәдер эзләгәндәй, куләгәләр арасыннан үрелеп-үрелеп карый да, кемнәндер оялган кебек, агач (башына / арасына / өстенә) кереп яшеренә. Елга тын. Инде ташу (ашкан / барган / киткән). Су кимүгә таба (китә / бара / җитә). Шуңа күрә елга, язгы ташу вакытындагыдай, биек ярлар өстенә бозлар төкерми, ул, йөгәнгә яңа гына өйрәтелгән ярсу тай кебек, күбеккә батканчы чапкан-чапкан да, буйсынып, тынып калган. (*Ф. Яруллиннан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноткалар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Укытучы

Уч төб...нә куеп Җирне гүя,
Бүге...гесен аның, үткәнен
Күрсәтте ул безгә
Урап кайттык
Күре...мәгән илләр үтәли.
Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәде <....>
- Яратыгыз Җирне! – диде ...аман,
- Мине яратыгыз! – димәде. (*Р. Гаташ*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

________________________________________________________

4. Беренче куплеттан капма-каршы мәгънәле сүзләрне күчереп языгыз. (**2 балл**)

___

5. Шигырьдән ясалма исемне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагызэ (**3 балл**)

___

___

6. Ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

___

7. Шигырьнең беренче куплетыннан алмашлыкларны күчереп языгыз, төрләнешен аңлатыгыз . **(6 балл)**

___

___

8.“*Матурлык эштә күренә*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2023-2024 нче уку елы 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 61**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Әйтелеше белән язылышы туры килми торган сүзләр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**
1) бәхет, рөхсәт
2) көләч, йомгак
3) китап, мәктәп
4) әнкәй, көнбатыш

2. Орфографик хаталы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) җөмхүрият
2) җәмгыять
3) җәрәхәт
4) җәмәгать

3. Җөмләдәге күчерелмә мәгънәдә килгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Әлбәттә, мәсьәлә ачык иде, ләкин идарәчеләр шулай да Казан кунагына карадылар. (А. Расих)*
1) мәсьәлә
2) Казан кунагы
3) карадылар
4) ачык иде

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*татар хатын-кызларының дугасыман итеп төрле төстәге тасмалар кыстырып тегелгән һәм тәңкәләр белән бизәлгән борынгы бизәнү әйбере*
1) алка
2) изү
3) йөзек
4) беләзек

5. Икеюллыктагы алмашлыкның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**
*Табиблар дәваламас авыруын наданның,*
*Дәвала белем белән наданлыгын аның*. (Й.Баласагунлы)
1) зат алмашлыгы
2) сорау алмашлыгы
3) күрсәтү алмашлыгы
4) юклык алмашлыгы

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Уйнавын да уйна,*
1) тик тә торма.
2) кешеләрнең хәлен дә бел.
3) ял да тә бел.
4) эшеңне дә уйла.

7. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
*Сагындырды сызылып таңнар атуы,*
***Әнкәемнең*** *иркәләп уятуы. (Җыр)*
1) аергыч
2) тәмамлык
3) аныклагыч
4) ия составында

8. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Иң аянычлысы шул иде: ата белән угыл арасында күзгә күренми торган бушлык барлыкка килде. (Н. Фәттах)*
1) иярчен ия җөмлә
2) иярчен хәбәр җөмлә
3) иярчен аергыч җөмлә
4) иярчен тәмамлык җөмлә

9. Җөмләдәге бәйлекне күчереп языгыз. **(2 балл)**
*Урта Азия чүлләренә, далаларына кадәр барып җиткәнбез. (Р.Миңнуллин)*
Җавап: ____ _____________________________________________

10. Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**
*Ул республика күләмендә үткәрелгән ярышларда катнашучы данлыклы йөзүче.*
Җавап: ______________

## II. Теоретик бирем.

Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**6 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкаль һәм андагы кош атамасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) Бакчасыз йортка ... кунмас. | 1) бөркет |
| Ә) ... һәр күлгә төшмәс. | 2) күке |
| Б) Иртә кычкырган .... башы авырта. | 3) аккош |
| В) ... биеклектән курыкмас. | 4) чыпчык |
| Г) Илдә ... үлми. | 5) былбыл |

**Җавап : ___________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Фәләхов елгыр бия янына килде. Ниндидер карарга килеп, ул кесәсенә тыгылды һәм аннан нәни генә пәке (чыгарды / бирде / капшады), авызлык турыннан ике яклап та йөгән каешын кисте. Ат сбруеның җаен ул яхшы белә, шуңа күрә каеш бөтенләй үк киселеп чыкмады. Алар иң (мөһим / әһәмиятле / кирәкле) вакытында – ат кузгалып киткәндә генә өзелеп чыгарга тиешләр.

Ниһаять, Фәләхов (азат / иркен / ирекле) сулыш алып, елгыр бияне бер ялгызын калдырып китеп барды. Ә атның үз хуҗасы – урман каравылчысы малае бу вакытта, ике кулына ике морожный (кыстырып / тотып / утыртып), чираттан чыгып килә иде.  Район сабан туеның ямьлелеге, гармун һәм җыр авазларыннан, чабышка әзерләнгән атларның матурлыгыннан башы әйләнгән чагы иде малайның. Аңардан да бәхетле кем булды икән бу (елда / мизгелдә / чорда), беркем әйтә алмый.

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Укытучы

Җир йөз...ндә иң-иң матур теләкләрне,
Сорасалар, багышларга кемгә, ди..п.
Әсир иткән үзенә күп йөрәкләрне
Укытучыма, ди...р идем, башым иеп!
Иң бәхетле кеше кем, дип сорасалар,

Әйтер идем сүзләремне, гөлгә төреп <....>
Ул – укытучы, елмайганда каршысында
Үзен...ән дә оста шәкертләрен күреп. (*Л. Шагыйрьҗан*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

4. Беренче җөмләдән тезмә сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

5. *Йөрәкләрне* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларныы күчереп языгыз. **(2 балл)**

8.“*Дуслык гамәлдә күренә*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2023-2024 нче уку елы 11 нчы сыйныф**

**ВАРИАНТ 2**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 61**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Авазның төп үзенчәлекләре буенча сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Тел алды тартыгы, йомык, саңгырау; түбән күтәрелешле, алгы рәт сузыгы, иренләшмәгән; ирен-ирен тартыгы, сонор.*

а) сан;

ә) фән;

б) тәм;

в) шәл.

2. Күчерелмә мәгънәдә килгән сүзе булган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Дусларны автобуска кадәр озата бардык.
2) Без гөлләргә су сибеп йөрибез.
3) Апам, бернигә дә карамыйча, хат язуын дәвам итте.
4) Бу китап 388 биттән тора икән.

3. Этнонимика терминына дөрес бирелгән аңлатманы билгеләгез. **(2 балл)**

1) тел белеменең кеше исемнәрен өйрәнә торган бүлеге;

2) тел белеменең төрле кушаматларны өйрәнә торган бүлеге;

3) тел белеменең төрле кабилә, халык исемнәрен өйрәнә торган бүлеге;

4) тел белеменең төрле торак пунктларның исемнәрен өйрәнә торган бүлеге.

4. Бирелгән мәгънәгә туры килә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Озынча тукыма кисәгеннән гыйбарәт билбау*
1) алъяпкыч
2) пута
3) күкрәкчә
4) каеш

5. Җөмләдәге сыйфат фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
*Бу җәһәттән ул төзекләндерүдән соң Казаныбызның 39 нчы мәктәбенә тапшырылачак Л.Толстой музеен мисалга китерде.* ("Мәдәни җомга")
1) җәһәттән
2) төзекләндерүдән
3) тапшырылачак
4) китерде

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Ук берне үтерсә,*
1) туп икене үтерер.
2) ул исән калмас.
3) тел меңне үтерер.
4) исе дөньяга сыймас.

7. Җөмләдә <...> тамгасы урынына тыныш билгесенең куелышы дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. **(2 балл)**
*Хәзер син әнә тегендә < ... > дөньяның икенче бер читендә кирәк.*
1) нокталы өтер куела
2) сызык куела
3) биредә өтер билгесе куела
4) биредә бернинди дә тыныш билгесе куелмый.

8. Җөмләдә ничә компонент булуы, аларның үзара ничек бәйләнүе һәм җөмләнең төре билгеләнгән җавапны күрсәтегез. (2 балл)

*Су буйларын яңгыратып,*

*Сызгырдым – борылмадың (Ә. Атнабаев)*

1) ике, санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;

2) бер, бу – гади җөмлә;

3) ике, аныклау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – иярченле кушма җөмлә;

4) ике, каршы кую интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

9. Җөмләдәге кушма сүзне күчереп языгыз. **(2 балл)**
*Беркөнне тәрәзәдән караса, үз күзләренә үзе ышанмады: ямь-яшел яфраклы Бакча чәчкәсе, көлә-көлә, җилдә тирбәлә. (Н.Каштан)*
Җавап: ______________________________________________________

10. Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

*Көн саен шулай Зөһрә мәктәптән йөгереп кайта да стенада эленеп торган календарь каршына килә. (Г.Гыйльманов)*

Җавап: _____________

## II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**6 балл**)

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкаль һәм андагы хайван атамасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) Авыр йөкне... тартыр. | 1) керпе |
| Ә) ... аягын күреп булмый. | 2) тычкан |
| Б) Араларыннан кара ... үткән. | 3) үгез |
| В) Койрыгына бассаң, .... дә чыелдый. | 4) мәче |
| Г) .... мөгезеннән эләктер. | 5) ат |

Җавап : ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Каз ул – **(кулга/өйгә/гаиләгә)** ияләштерелгән иң борынгы йорт кошларының берсе. Халык **(элек-электән/борынгы заманнан/борыңгы чордан)** **(чиксез / күп / гаять)** итеп каз асрарга яраткан. Беренчедән, аның мамыгыннан мендәр, түшәк-ястыклар ясаганнар. Мендәрләрдән башка авыл йортын күз алдына китереп буламы соң? Икенчедән, каз итеннән бик **(оста/уңган/дөрес)** итеп әзерләгән каз бәлешенә, каз тәбикмәгенә, какланган казга җитәме соң!

Каз – туйларның да төп **(күрке/асылы/гаяте)**. Чөнки кыз яки улның туен үткәргәндә пар каз **(борынгыдан/элеккеге/бер вакыттан)** инде туйның хөрмәтле кучтәнәче булган. Хәер, бүген дә туйларда каз чыгару йоласы яшәп килә әле. Бу **(йола/гадәт/очрак)** ул эш кенә түгел, матур итеп аралашу, күңел ачу, үзеңне күрсәтү чарасы да. *(Вакытлы матбугаттан)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Ак кәгазьдән к...ләм эзе тиз җуела,
Караны да, тушьларны да җуеп була.
Ташка язган сүзләрне дә еллар ала.
Күңелләргә язылган сүз мә...ге кала.

Синең бурыч <....> күңелләргә сүзләр язу,
Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу.
Әзер юлдан үз көеңә бару җиңел.
Тигез җирдә юл салу да а...ыр т...гел. (*Э. Мөэминова*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

4. *Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу* җөмләсеннән күчерелмә мәгънәле сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

5. Беренче куплеттан сыйфат фигыльләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

7. *Ташка язган сүзләрне дә еллар ала* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(2 балл)**

8.“*Күңелгә язылган матур сүз*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)